Муниципальное бюджетное общеобразовательное учрежд
«Салаушская средняя общеобразовательная школа» Агрызск
муниципального района Республики Татарстан

| «Рассмотрено» | «Согласовано» | «Утверждаю |
|---|---|---|
| Руководитель МО | Заместитель директора по УВР. | Директор МБО Салаушская СОШ |
| Закирова Л.М. | Фархушина Л.Г. | Ахметзянова Л.М. |
| Протокол № 1 | от «31» августа 2023 г. | Приказ № 100-О |
| «29» августа 2023 г. | | «31»августа 2023 |

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

учебного курса внеурочной деятельности

«Волшебный театр» («Тылсымлы театр»)

для 1-4 классов

уровня начального общего образования

2023-2024 учебный год

Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение
«Салаушская средняя общеобразовательная школа»
Агрызского муниципального района Республики Татарстан

| **«Рассмотрено»** | **«Согласовано»** | **«Утверждаю»** |
|---|---|---|
| Руководитель МО<br>_____ Закирова Л.М.<br>Протокол № 1<br>«29» августа 2023 г. | Заместитель директора по УВР.<br>______ Фархушина Л.Г.<br>от «31» августа 2023 г. | Директор МБОУ Салаушская СОШ<br>___________<br>Ахметзянова Л.М.<br>Приказ № 100-О<br>«31»августа 2023 г. |

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

учебного курса внеурочной деятельности

«Волшебный театр» («Тылсымлы театр»)

для 1-4 классов

уровня начального общего образования

2023-2024 учебный год

**Аңлатма язуы**

"Хәтердән башка йолалар, тәрбиядән башка рухи хәзинә, рухи хәзинәдән башка шәхес, ә шәхестән башка халык - тарихсыз"- дип әйтелә халыкта.

Бала күңелен ап-ак кәгазь белән чагыштыралар. Шул кәгазьгә ничек итеп матурлык, шәфкатьлелек бөртекләрен чәчәргә соң? Әлбәттә, әдәбият-сәнгать аша. Әдәбият, сәнгать белән кызыксынган, китапларны чын күңеленнән яратып укыган баланың белеме дә тирәнрәк, күңеле дә байрак була. Аның күркәм эшләр башкарырга омтылышы да көчәя.

Кешеләрнең үз- үзләрен тоту кагыйдәләр җыелмасын тәшкил итүче сөйләм этикеты халыкның мәдәнилек дәрәҗәсен билгели торган иң мөһим өлешләрнең берсе булып тора. Сүз сәнгате - халык байлыгы, ул аның тормышы, кызыксынулары, теләкләренә бәйле. Сәнгать, әдәбият телдән башка үсә алмый, чөнки тел – аралашу чарасы, көрәш коралы.

Безнең илдә һәр милләт кешесе үз телендә белем алырга, җәмәгать оешмаларында сөйләшүләр алып барырга һәм җыелышларда үз телендә чыгыш ясарга хокуклы. Тел – милләт байлыгы. Тел булмаса, милләт тә юк.

Әлеге программада башлангыч сыйныфта яңалык булып килеп кергән Федераль Дәүләт белем бирү стандарты буенча укытуда укучыларның дәрестән тыш эшчәнлеген оештыру буенча эш программасы урын алды.Укучылар эшчәнлеген оештыруның эстетик - сәнгать юнәлеше - театр түгәрәге эше тәкъдим ителә.

Бу түгәрәк укучыларның артистлык сәләтен, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен, логик фикерләүләрен үстерү максатыннан чыгып оештырыла. “Тылсымлы театр” түгәрәге, исеменнән үк күренгәнчә, театр, сәнгать, җыр-бию яратучы укучыларны туплый. Бу түгәрәк, шулай ук, сәхнә серләренә төшенү, кулдан матур киемнәр әзерләү һәм зәвыклы киенү, тамашачылар алдында үз-үзеңне тотарга өйрәнү бурычларын үз эченә ала.

Түгәрәктә сәләтле балалар белән күмәкләп һәм индивидуаль эшләү урын ала.
“Тылсымлы театр” драма түгәрәге берләшмәсенә 7-10 яшьлек укучылар туплана. Дәресләр атнага 1 сәгатьтән елга 34 сәгать үткәрелә.

Максат:

Шәхес формалаштыруга юнәлтелгән технология аша укучыларда әдәбият-сәнгатькә мәхәббәт тәрбияләп, иҗади үсеш булдыру.

Бурычлар:

- укучыларны түгәрәк эшенә җәлеп итү, театр сәнгате белән кызыксыну уяту;
- сәнгать әсәрләренә мәхәббәт уяту;
- укучыларның артистлык сәләтен, иҗади талантларын күрә, уңышларга дәрт уята алуга ирешү;
- сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү. сөйләгән чакта җаваплылык хисе тоярга, авазларны аңлаешлы итеп әйтергә өйрәтү;
- әдәби сөйләм кагыйдәләрен төшендерү, сүзне ничек әйтергә икәнен аңлату, әдәби әсәрне матур итеп укырга, дөрес аңларга, нык үзләштерергә әзерләү;
- халкыбызның милли традицияләре турындагы күзаллауны ныгыту;
- телебезнең матурлыгын күреп яратырга өйрәтү.

**Түгәрәкнең юнәлеше**

- балаларның эстетик зәвыгын, иҗади фантазияләрен үстерү;
- балаларны традицияләребезгә нигезләнгән үзара аралашу культурасын аөйрәтү;
- балаларның милли телен баету, туган ягыбызның гореф-гадәтләренә карата кызыксыну уяту, мәхәббәт тәрбияләү;
- сәләтле балаларны ачыклау.

**Көтелгән нәтиҗәләр һәм аларны тикшерү төрләре**

- уку елы ахырына матур итеп шигырь, экият сөйләүләренә аларны сәхнәләштерергә өйрәнүләренә ирешергә;
- үз-үзләрен сәхнәдә матур, иркен итеп тота белүләренә ирешергә;
- укытучылар бәйрәме көнендә чыгыш әзерләргә;
- яңа елга әкият-тамашалар сәхнәләштерергә;
- “Сөмбелә”, “Өлкәннәр көне”.”Әниләр көне”, “Яңа ел”, Муса Җәлил туган көн, “Туган тел”көне, 23 февраль, 8 март.”, “Нәүрүз”, “Кошлар көне, Г.Тукай туган көнендә, Җиңү көне бәйрәмнәрендә чыгыш ясарга; кечкенә күләмле әсәрлр сәхнәләштерү;
- милли уеннар, биюләр, җырлар, нәфис сүз белән сәхнәдә чыгыш ясарга, концерт номерлары башкарырга.

**Программа эчтәлеге**

**I. Кереш (1 сәг.)**

Кереш дәрес. Укучыларны туплау, түгәрәкнең эш планы таныштыру. Инструктаж үткәрү.

**II. Яшь артистлар булырга әзерләнәбез (2 сәг.)**

Укучыларның сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү. Сәхнә серләренә өйрәнү. Киенү-бизәнү осталыгы турында сөйләшү, сәхнәдә нәфис сүз белән чыгышлар карау.

Татар халык иҗаты белән танышу. Татар халык иҗатының үзенчәлекләрен билгеләү. Индивидуаль рәвештә җырлар, биюләр өйрәнү. Киемнәр әзерләү.

Татар халкының сәхнә уеннары, такмак, такмаза, тел шомарткычлар турында мәгълүмат бирү. Сәхнә өчен куелган уеннарны өйрәнү, сәхнәдә кую.

Балаларны парлы, күмәк биюләргә өйрәтү (бию элементларын кабатлау, көйгә басу, киемнәр әзерләү). Бәйрәмнәрдә чыгыш ясау.

**III. Театраль тамашалар (22 сәг.)**

"Сөмбелә", "Өлкәннәр көне"."Әниләр көне", "Яңа ел", Муса Җәлил туган көн, "Туган тел"көне, 23 февраль, 8 март.", "Нәүрүз", "Кошлар көне, Г.Тукай туган көнендә, Җиңү көне бәйрәмнәренә әзерлек эшләре алып бару, киемнәр әзерләү. Тамаша залын бизәү.

Спектакль өчен рольләр сайлау, кабатлау. Музыка сайлау. Декорация, киемнәр әзерләү.Театраль тамашалар кую.

Җырлы-биюле, такмаклы уеннар өйрәнү. Төрле кичәләрдә уеннар белән катнашу. Бүгенге көндә экологик проблема һәм аның әһәмияте. Табигатьне саклауга өлеш кертү: тирә-юньнең чисталыгын саклау, агачлар утырту, чишмәләрне чистарту, кошларга, җәнлекләргә карата мәрхәмәтле булырга кирәклеген төшендерү. Экологик темага кичә, КВН, конкурслар үткәрү. "Кошларны таныйсыңмы? дип исемләнгән музыкаль театр-тамаша өйрәнү, чыгыш ясау.

Кызыклы спорт уеннары өйрәтү, күңелле ярыш-эстафета оештыру. Ярыш өчен киемнәр, эмблема әзерләү.

Спорт уеннары барышында тәнәфесләр вакытында катнашу өчен биючеләр әзерләү. (Кечкенә һәм өлкән группалар). "Сәламәтлек театры" әзерләү һәм чыгыш ясау.

**VI. Театраль тамашаларга биюләр, җырлар өйрәнү (8 сәг.)**

Театр атналыгы оештыру (атналык программасы аерым төзелә). "Мәктәп йолдызлары" атналыкларында катнашу өчен сәхнә әсәрләре сайлау.

Балалар өчен язылган җырлар тыңлау. Иң матур җырларны өйрәнү, сәхнәдә башкарырга (аерым, күмәк) әзерләнү. Җырга карата киемнәр сайлау.

Кызлар-малайлар белән вальс, заманча биюләр, милли биюләр өйрәнү.

**VIII. Йомгаклау (1 сәг.)** Түгәрәк эшенә анализ, йомгак

Барысы: 34 сәгать

**Ralендарь-тематик планлаштыру**

| № | Бүлек исеме | Сәгатьләр саны | Тема | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Календарь | Фактик |
| 1. | Кереш | 1 | Укучыларны туплау. Түгәрәкнең эш планы белән таныштыру. Инструктаж үткәрү<br>Без - яшь артистлар<br>Сөйләм этикеты. Тизәйткечләр. “Мин татарча сөйләшәм” | **7.09.** | |
| 3 | Яшь артистлар булырга әзерләнәбез | 2 | “Мин татарча сөйләшәм” Сәхнә серләрен өйрәнү. Видеоязмалар карау.<br>Киенү-бизәнү осталыгы. Декорациянең роле.<br>Якташ язучыларыбыз, шагыйрә, шагыйрьләребез белән аларның иҗаты белән танышу, шигырьләрен өйрәнү. Сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү. | **14.09**<br>**21.09** | |
| 4-25 | **Театраль тамашалар** | 22 | Сөмбелә-<br>Өлкәннәр көне-<br>“Яшь бөркетләр”оешмасына керергә әзерлек<br>Әниләр көненә әзерлек<br>“Куш кулым” җырлы -бию | **28.09**<br>**9.11**<br>**16.11**<br>**23.11**<br>**30.11** | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | Конкурс “Туган телем-серле тел” (әзерлек)<br>“Исәнме, чыршыкай”<br>Яңа ел-<br>“Суык бабай” | **7.12**<br>**14.12**<br>**21.12**<br>**28.12** | |
| | | | Татар халык биюе<br>“Салют синҗа, Муса Җәлил” | **11.01**<br>**18.01**<br>**25.01** | |
| | | | “Матур булсын”<br>Туган тел көне<br>“Туган телем татар теле”<br>Муса Җәлил туган көн<br>23 февраль- | **1.02**<br>**8.02**<br>**15.02**<br>**22.02**<br>**29.02** | |
| | | | 8 март 2 сәг<br>Нәүрүз -5 сәг. | **7.03**<br>**14.03**<br>**21.03** | |
| | | | Кошлар көне -1 сәг.<br>Г.Тукай туган көне- 4 сәг. | **4.04**<br>**11.04**<br>**18.04**<br>**25.04** | |
| | | | Җиңү көне – 4 сәг.<br>Соңгы кыңгырау -1 сәг. | **2.05**<br>**16.05**<br>**23.05** | |
| 26-33 | **Театраль тамашаларга биюләр, җырлар өйрәнү** | 8 | “Күз җитте” җыры | **5.10** | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | “Рәхмәт сезгә<br><br>“Бәхет өчен” | **12.10** | |
| | | | “Кояшлы ил, безнең ил” | **19.10** | |
| | | | “Түбәтәй” җырлы -бию | **26.10** | |
| | | | “Карлыгач” | **21.03** | |
| | | | “Бабай югалган”<br><br>“Күрәсем килә”, | **25.04** | |
| | | | “Җәй” | **2.05** | |
| | | | “Җәйге яңгыр” | **16.05** | |
| 34 | Йомгаклау. | 1 | Күңелле ял. Түгәрәк эшенә анализ, йомгак | **23.05** | |

**Кулланылган әдәбият**


1. Алиш А. “Хикәяләр һәм әкиятләр”, Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1991
2. Галиева Л.И., Баязитова Л.В. “Көч һәм рух тамырлары”Казан: “Мәгариф”, 2000
3. Зарипова Ф.Я.”Могҗизалы мәктәп сәхнәсе”, Казан: “Мәгариф”, 2003
4. Казыйханов В. “Әхлак дәресләре”, Яр Чаллы: “Иҗат”, 1998
5. Мазин И. “500 загадок для детей”, Москва: ООО “ТЦ Сфера”, 2003
6. Мөҗәһит “Акыллыга сүз әйттем”, Казан: “Мәгариф”, 2003
7. Лях В.И. “Физкультура – минем дустым”, Москва: “Просвещение”, 2001, Казан: “Тарих”, 2002
8. Рахимов И.И “Хищные птицы и совы Татарстана”, Казань: Татполиграф, 1999
9. Фәйзи Җ. “Халык җәүһәрләре-күңелем кыллары”, Татарстан китап нәшрияты, 1987
10. Халикова Р.Ш. “Раушан көзге”, Казан: “Мәгариф”, 1993
11. Шаехова Р.К. “Ступеньки к творчеству”, Казань: “мастер Лайн”, 2000
12. “Татар балалар фольклоры”, Казан: “Хәтер”, 2009

13. “Татар халык әкиятләре”, Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1990
14. “Татар балалар әдәбияты”серия “МК”, 19-20 том, Казан: “Тарих”, 2003
15. “Тылсымлы хикәяләр” серия “МК”, Казан: “Тарих”, 2003
16. “Татар халык уеннары”, серия “Энҗе чәчтем, энҗе җыям”, Казан: “Мәгариф”, 2003
17. “Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар”, Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1987
18. “Татар халык иҗаты. Табышмаклар”, Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1988
19. “Татар халык җырлары”, Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1987
20. “Татарские танцы”, Казань: “Магариф”, 2002

**Эчтәлек**

**1. Аңлатма язуы...................................................................................... 2 нче бит**

**2. Программа эчтәлеге........................................................................... 3 нче бит**

**3. Календарь-тематик план......................................................................5 нче бит**

**4. Кулланылган әдәбият.................................................................... 8 нчы бит**